

Ике ел яшәv дәверендә Кадошкино районы Латышовка авылы “Шәфкать (Милосердие)” дигән волонтерлар оешмасы вәкилләре белән кvп эшләр башкарылган.
Ин жаваплысы – Боек Ватан сугышында батырларча вафат булган авылдашлары Обелискын хормәтләп жыештыру. Мәктәп укучылары вафат булганнарнын списогын барлау буенча зур эш алып баралар. Шулай, Боек Ватан сугышы кырларында Латышовка авылы кешеләренен жиде исемен таптылар;бvгенгә 139 батыр булды.
«Үлемсез полк» акциясен vткәрv очен зур эш алып барды «Шәфкать» оешмасы вәкилләре. Сугыш ветераннарынын 80 фотографиясен жыеп алдылар һәм 9 майда, Жинv конендә, Латышовка гомуми белем бирv мәктәбе коллективы әбиләре, бабайкалары фотографияләрен кvтәреп авыл урамы буенча vттеләр. Мәдәният йортында III дәрәжә Хезмәт Даны һәм башка орденнар иясе Таһир Әхмәт улы Донской белән жылы очрашу оештырып vткәрделәр. Очрашуда сугыш еллары хезмәткәренен тырыш хезмәте турындагы хикәяләvне зур кызыксыну белән тынладылар. Боек Ватан сугышы ветераннары ой алларын жыештырырга ярдәм итәләр волонтерлар. Инсар шәһәре картлар йортында концертлар vткәрv традициягә кереп бара. «Жинv Урманы» акциясе кысаларында 200дән артык чыршы авыл территориясендә утырттылар, «Жинv сирене»ндә - 50 топ сирень куагы.
Белгәнебезчә, Латышовка авылыннан Боек Ватан сугышына 300 кеше китә. 139ы аннан кайтмый. Жинv коне алдыннан ел саен «Хәтер вахтасы» vтә. «Шәфкать» отряды белән Боек Ватан сугышы ветераннарынын фотографияләре һәм биографик белешмәләре белән «Хәтер дивары - Стена Памяти» ясап элгәннәр. Алар һәрвакыт хәтердә. Эшләгәннәргә эш житә. Ике ел эчендә «Чистый обелиск», «Чистое село», «Свеча памяти», «Бессмертный полк», «Наказу героев верны!» акцияләрендә катнаштылар. Волонтерлар оешмасы активистлары торле кvләмдәге торле ижади конкурсларда да катнаштылар. Кайберләрен атап vтәбез: «Живая классика», «Наследие Победы», «Одаренные дети», «Мы выбираем будущее», «Калейдоскоп профессий», «Цена Победы» һәм башкаларында. Латышовка волонтерлары тырышып эшли. Алда яна планнар. Тагы да тырышып эшләргә теләкләре бар.

Светлана Поташова